КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 24 май г.Казань № б-978

Интеллектуаль һәм иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү һәм аларны бүләкләү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2021 елның 19 июненнән 2 августына кадәр «Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумының (алга таба – Форум) алты сменасын үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

«Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумының алты сменасын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын;

«Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумының алты сменасын әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара планны.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Форумда катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе белән берлектә:

Биләр дәүләт тарих-археология табигать музей-тыюлыгы территориясендә, Форум үткәрү территориясендә иминлекне һәм гадәттән тыш хәлләрне профилактикалауны тәэмин итүне тикшерүдә тоту үтәлеше буенча чаралар күрергә;

министрлык хезмәткәрләренең Форум үткәрү урынында кизү торуын тәэмин итәргә;

чараны оештыручыларга гамәлдәге законнар кысаларында Биләр дәүләт тарих-археология табигать музей-тыюлыгы территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Форумда катнашучылар (Татарстан Республикасыннан гомуми белем бирү оешмалары укучылары) составын формалаштыруда булышлык күрсәтергә.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына республика, шәһәр һәм район басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында Форумны мәгълүмати яктыртуда ярдәм күрсәтергә.

7. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә Форумны әзерләү һәм үткәрү чорында санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Биләр дәүләт тарих-археология табигать музей-тыюлыгы территориясендә, Форум үткәрү территориясендә иҗтимагый тәртипне тәэмин итүдә оештыручыга ярдәм күрсәтүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Форумны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүне.

8. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 24 май, б-978 нче
боерыгы белән расланды

«Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумының алты сменасын әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара планы

| Т/с | Чара исеме | Үткәрү башкару | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | «Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумының (алга таба – Форум) алты сменасын әзерләүне һәм үткәрүне административ тәэмин итү | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |
| 2. | Санитария-эпидемиология законнары таләпләрен үтәп, Форум үткәрү өчен палаткалардан торган шәһәрчек кору һәм урнаштыру, шул исәптән, палаткалардан торган лагерьның санитария законнары таләпләренә туры килүен билгели торган санитария-эпидемиология бәяләмәсен алып («Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, аларның ялын һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларына карата санитария-эпидемиология таләпләре» 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләре һ.б.), яңа коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау мәсьәләләре буенча эш оештыру.<br>Алдан (эшкә урнашканда) һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен үтүгә кагылышлы таләпләргә (Россия | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләргә мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне, шулай ук мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләре үткәрелә торган эшләрне башкаруга карата медицина күрсәтмәләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 29н номерлы боерыгы) туры килә торган, һөнәри гигиена әзерлеге һәм аттестациясе, вакцинациясе, медицина тикшеренүләре һәм лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре күрсәтелгән, прививкалар, авырган йогышлы авырулары турында, эшкә рөхсәт итеп, һөнәри гигиена әзерлеге һәм аттестация узу турында мәгълүматлар бирелгән шәхси медицина кенәгәсе булган хезмәткәрләрне җәлеп итеп, Форум эшен оештыру.<br>Һәр смена башлану алдыннан Форум персоналында яңа коронавирус йогышлы авыруы булу-булмауга тикшерү оештыру (тикшерү, Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән диагностика препаратларын һәм тест-системаларын кулланып, яңа коронавирус йогышлы авыруын тудыручының генетик материалын яки антигеннарын билгели торган ысулларның теләсә нинди белән гамәлгә ашырыла һәм тикшерү нәтиҗәләре эшкә чыгу көненә кадәр кимендә өч календарь көн алдан бирелә). | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Профилактика һәм дезинфекция чараларын үткәрү, палаткалардан торган шәһәрчекнең туклану блогы хезмәткәрләре арасында яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны кисәтү буенча санитария законнары таләпләрен исәпкә алып, туклануны оештыру, шул исәптән һәр смена башлану алдыннан эчәк инфекцияләренең норо-, рота- һәм башка вирус тудыручыларның булу-булмавына тикшерү үткәрү (эшкә чыгу көненә кадәр кимендә өч календарь көн алдан)<br>Форум үткәрү территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү. Гадәттән тыш хәлләрдә гамәлләр планын эшләү.<br>Иҗтимагый тәртипне саклауны оештыру. Форум үткәрү территориясен күчмә киртәләр һәм коймалар белән әйләндереп алу.<br>Форумның тикшереп үткәрү пунктларында ике данәдә аркалы металл детекторларын, ике данәдә кул металл детекторларын урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү.<br>Объектны саклауны һәм үткәрү режимын тәэмин итү өчен хосусый саклау оешмасы белән шартнамә төзү | | |
| 3. | Форумда катнашучыларны һәм аның кунакларын «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракларга, торак урыннарга, җитештерү, җәмәгать урыннарын файдалануга, санитария-эпидемиягә каршы (профилактика) чаралар оештыруга һәм үткәрүгә карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.1.3684-21 | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | нче СанПиН таләпләренә җавап бирә торган яхшы сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү системасын тормышка ашыру | | |
| 4. | Форум территориясендә дератизация чаралары (лагерь, лагерь территориясе тирәли киртә 200 метр) һәм акарицидлар (лагерь, лагерьның яшел территориясе тирәли киртә 50 метр) белән түбәндәгечә эшкәртүләр үткәрүне тәэмин итү:<br>дератизация чаралары белән – нәтиҗәлелеген бәяләп, Форумны ачуга кадәр 30 көн кала; контроль һәм зоологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча сменалар (лагерь территориясе) арасында;<br>акарицидлар белән – эшкәртүләрнең нәтиҗәлелеген ике тапкыр бәяләп (акарицидлар белән эшкәрткәннән соң 3 – 5 көннән һәм 15 – 20 көннән соң), Форумны ачуга кадәр 20 көн кала, сменалар арасында – эпидемик күрсәткечләр булганда.<br>Форум территориясендә урнашкан табигый сулыкка карата «Россия Федерациясе территориясендә паразитар авыруларны профилактикалау» дигән 3.2.3215-14 нче СанПиН таләпләре нигезендә энтомологик һәм дезинсекция чараларын үткәрүне тәэмин итү | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |
| 5. | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең палаткалы типтагы балалар лагерьлары иминлеген тәэмин итү турындагы 2019 елның 1 августындагы 18-19р номерлы боерыгы нигезендә куәте, шул исәптән Форум планы нигезендә территория буенча электр кирәк- | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | ираклары һәм электр тапшыру линияләрен Форум территориясеннән читкә чыгару кирәкле күләмдә булган өзлексез һәм куркынычсыз электр белән тәэмин итү системасын тормышка ашыру.<br>Форумны үткәрү көннәрендә челтәр коммуникацияләренә техник хезмәт күрсәтүне тәэмин итү | | |
| 6. | Форум планы нигезендә, автотранспортны вакытлыча куеп тору урынын ясап, Форум территориясенә бик озын йөк һәм пассажирлар транспорты белән йөрү мөмкинлеген тәэмин итү | 2021 елның июне – июле | Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), «Алексеевскдорстрой» ачык акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |
| 7. | Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында мәгариф оешмалары, балалар һәм яшьләр өчен башка социаль инфраструктура объектлары корылышына, аларны тотуга һәм аларның эшен оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 3.1/2.4.3598-20 нче СП санитария-эпидемиология кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июнендәге 16 номерлы карары, «2021 елда COVID-19 таралу рисклары саклану шартларында балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары эшен оештыру буенча тәкъдимнамәләр» дигән 3.1/2.4.0239-21 нче МР методик тәкъдимнамәләр нигезендә балалар йөртү шартларын тәэмин итеп, Форумны оештыручыларга катнашучыларны һәм кунакларны илтүдә кирәкле ярдәм күрсәтү | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 8. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан бүлеп бирелгән һәм планлаштырылган маршрут буенча балаларны йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт чараларын «ГЛОНАСС+112» дәүләт мәгълүмат системасы аша мониторинглауны һәм күзәтүне тәэмин итү | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә системасы дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| 9. | Юлга чыгу көненә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында мәгариф оешмалары һәм балалар һәм яшьләр өчен башка социаль инфраструктура объектлары корылышына, аларны тотуга һәм аларның эшен оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 3.1/2.4.3598-20 нче СП санитария-эпидемиология кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июнендәге 16 номерлы карары, «2021 елда COVID-19 таралу рисклары саклану шартларында балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары эшен оештыру буенча тәкъдимнамәләр» дигән 3.1/2.4.0239-21 нче МР методик тәкъдимнамәләр нигезендә балалар йөртү шартлары тәэмин ителгән, маршрутлары, китеп бару һәм килеп җитү вакытлары күрсәтелгән балалар йөртүче транспорт чаралары исемлеген Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы адресына җибәрү. | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары (килешү буенча) |
| 10. | «ГЛОНАС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасында балалар йөртүче транспорт чараларын (машина йөртүче | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | кабинасы белән тавыш ярдәмендә элемтәгә керү аппаратурасы һәм тревога төймәсе төзеклеген кертеп) мониторинглау һәм диспетчерлау өчен һәркем файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | | |
| 11. | Кирәк булуга карап абонент терминалларын тоташтыру мөмкинлеге белән балалар йөртүче транспорт чараларын мониторинглау һәм диспетчерлау өчен «ГЛОНАС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасының өзлексез эшкә сәләтле булуын тәэмин итү.<br>«ГЛОНАС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы эшендә тоткарлыклар булганда консультация ярдәме һәм техник ярдәм күрсәтү өчен тәүлек буена эшли торган телефон элемтә линиясен оештыру, элемтәгә керү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына телефон номеры турында мәгълүмат бирү | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы |
| 12. | Форумны әзерләү һәм үткәрү (программа, сценарие, административ хезмәт күрсәтү, транспорт хезмәте күрсәтү, Форум бренды һәм басма-полиграфия продукциясе, заказ, кирәкле техник һәм видеопроекция җиһазларын монтажлау һәм монтажлау).<br>Фотога һәм видеога төшерүне оештыру.<br>Чараны һәм катнашучыларны иминләштерүне тәэмин итү | 2021 елның июне – августы | «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |
| 13. | Форумны медицина белән тәэмин итүне оештыру | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 14. | Форумның оештыру комитетына яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) тест үткәрүдә ярдәм күрсәтү | 2021 елның июне – августы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 15. | Биләр дәүләт тарих-археология табигать музей-тыюлыгы территориясендә, Форум үткәрү территориясендә ижтимагый тәртипне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү | 2021 елның 19 – 23 июне, 2021 елның 29 июне – 1 августы, 2021 елның 4 – 9 июле, 2021 елның 14 – 18 июле, 2021 елның 22 – 26 июле, 2021 елның 29 июле – 2 августы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 16. | Чара оештыручыларга гамәлдәге законнар кысаларында Биләр дәүләт тарих-археология табигать музей-тыюлыгы территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү | 2021 елның 19 – 23 июне, 2021 елның 29 июне – 1 августы, 2021 елның 4 – 9 июле, 2021 елның 14 – 18 июле, 2021 елның 22 – 26 июле, | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | 2021 елның 29 июле – 2 августы | |
| 17. | Форумны әзерләү һәм үткәрү чорында санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | 2021 елның 1 июне – 31 августы | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 18. | Форумны республика, шәһәр һәм район басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктырту.<br>Форум үткәрү турында мәгълүмат бирү сюжетларын әзерләү һәм трансляцияләү | 2021 елның июне – августы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 24 май, б-978 нче
боерыгы белән расланды

«Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумының алты сменасын
әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Бариев Марат Мансур улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Физик культура, спорт, туризм һәм яшьләр эшләре комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| Биктимеров Марат Таһир улы | Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Волынец Ирина Владимировна | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Габдрахманова Айгөл Таһир кызы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт» яшьләр үзәге дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Гыйниятов Данил Шамил улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыятенең башкарма директоры урынбасары – сәнгать тапшырулары буенча баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Егоров Андрей Вячеславович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Зарипов Айрат Ринат улы | алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Руденко Евгений Анатольевич | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Сергеев Сергей Валентинович | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы урынбасары – Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Симашева Альбина Валентиновна | Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы | «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрның беренче урынбасары |
| Усманова Гүзәл Салават кызы | «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фондының Инициативалар үзәге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хисамиев Марат Рамил улы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәт-тәшлек итү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы. |